**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**НИЖНЕКАРМАЛКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423102, СЕЛО НИЖНЯЯ КАРМАЛКА, УЛ.ЛЕНИНА, Д.44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ТҮБӘН КАРМАЛКА АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

423102, ТҮБӘН КАРМАЛКА АВЫЛЫ, ЛЕНИН УРАМЫ, 44 ЙОРТ

Тел.: (84396)2-39-47 ФАКС: (84396) 2-39-47
Email: Nkar.Cmn2@tatar.ru

**17 декабрь 2025 ел** **№ 10**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Түбән Кармалка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елга җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатен карау хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 24.5 статьясына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 77 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 октябрендәге 288-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Башкарма комитетның 2025 елның 02 декабрендәге № 129 карарын карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кармалка авыл җирлеге бюджетына бюджет ассигнованиеләренең җитәрлек булмавын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кармалка авыл җирлеге башкарма комитеты мөрәҗәгатендә күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә аерым вәкаләтләрне финанслаудан кушымта нигезендә баш тартырга.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Түбән Кармалка авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.Ф. Митякин

Түбән Кармалка авыл җирлеге
Советының 2025 елның 17 декабрендәге
10 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Башкарма комитет өчен 2026 елда бюджет ассигнованиеләрен бүлеп бирү өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләр исемлеге**

| № п\п | Бюджет ассигнованиеләре белән ныгыту өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрнең аталышы | БАРЛЫГЫ мең сумнарда |
| --- | --- | --- |
| 1. | Су белән тәэмин итүгә лицензия алу өчен документлар әзерләү | 350 |
| 2. | Җир асты чыганакларын санитар саклау зоналары проектын эшләү | 120 |
| 3. | Янгын гидрантларын ремонтлау һәм алыштыру | 150 |
| 4. | Дератизация чараларын үткәрүне тәэмин итү | 60 |
| 5. | Кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны норматив хәлдә тоту өчен махсус реагентлар сатып алу | 50 |
| 6. | Санкцияләнмәгән чүплекләрне рекультивацияләү | 1000 |
| 7. | Янгын сүндергечләр сатып алу, тутыру | 10 |
| 8. | Авыл мәдәният йортында һәм Авыл клубында янгынга каршы чаралар (түбә һәм сәхнә тартмасы пропиткасы) | 300 |
| 9. | Янгын сүндерү сигнализациясен ремонтлау | 120 |
| 10. | Металлодетекторлар сатып алу | 40 |
| 11. | Авыл мәдәният йортында һәм Авыл клубында Террорчылыктан саклануны куркынычсызлык паспортлары нигезендә китерү ( тавыш белән ашыгыч хәбәр итүнең автоном системасын урнаштыру) | 30 |
| 12. | Видеокүзәтү системасын урнаштыру, ремонтлау | 200 |
| 13. | Юл билгеләрен урнаштыру | 100 |
| 14. | Янгынга каршы минераллаштырылган полосалар булдыру | 100 |
| 15. | Гидрант күрсәткечләрен урнаштыру | 100 |
| 16. | Эшләрнең башка төрләре | 300 |
| 17. | Мәдәният йортында электр үткәргечләрен ремонтлау һәм алыштыру | 1000 |
| | **БАРЛЫГЫ:** | **4330,0** |